ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

26.01.2023                                        01

пос. Октябрьский

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә 2023нче елда җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 7793 сум 48 тиен күләмендә билгеләргә һәм 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

ТР Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы                                        Ш.Р. Азизов

Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2023нче
елның 26 гыйнварыннан 1
номерлы карарына

1 нче кушымта

.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә 2023нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4029,78 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1249,40 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2514,30 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2023нче елның 26 гыйнварыннан 5 номерлы карарына

2нче кушымта

.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә 2023нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Тәнне төрү | 745,61 |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3284,17 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1249,40 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2514,30 |
| Барлыгы | 7793,48 |